Ятмас Дусай авыл җирлеге Советы

КАРАР

«15» апрель 2025 ел №09

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Ятмас Дусай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы – Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлеге, кыскартылган атамасы – Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай авыл җирлеге (текстта алга таба – җирлек).».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас Дусай территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы А.И.Шаймарданова